АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**«31» июль 2018 ел** **№ 34**

Казан ш.

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге № 112 Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 14 мартындагы № УП-127, 2015 елның 11 декабрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарны тестлауны оештыру мәсьәләләре» № УП-1192 Указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 мартындагы № 397 карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертелүгә конкурслар үткәрүнең Бердәм методикасы нигезендә.

БОЕРУ:

1. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында Нигезләмәне расларга.

2. «Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс турында» Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының 25.11.2017 № 33 боерыгын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотам.

Җитәкче Т.И. Миңнуллина

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы боерыгы белән
РАСЛАНГАН
2018 елның «31» июленнән
№ 34

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕНЕҢ ВАКАНТЛЫ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮГӘ (КАДРЛАР РЕЗЕРВЫНА КЕРТҮГӘ) КОНКУРС ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү тәртибен, шартларын һәм методикасын билгели (алга таба - конкурс).

Конкурс Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә (алга таба - граждан хезмәте) тигез үтеп керү хокукын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба - граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфаи үсеш хокукын тәэмин итә.

1.2. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында (алга таба - Агентлык) Конкурс «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль законның (алга таба - Федераль закон) 22, 64 статьялары, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге № 112 Указы, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмати системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2017 елның 3 мартындагы № 256 һәм «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертелүгә конкурслар үткәрүнең Бердәм методикасын раслау турында» 2018 елның 31 мартындагы № 397 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 14 мартындагы № УП-127 һәм 2015 елның 11 декабрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарны тестлауны оештыру мәсьәләләре» № УП-1192 Указлары нигезендә үткәрелә.

Конкурс Агентлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасы) биләп торуга кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның әлеге вазифаны биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Агентлыкта граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләп торуга Конкурс Агентлык җитәкчесе карары белән граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы булганда игълан ителә, аны биләп тору Федераль законның 22 статьясына туры килеп конкурс нигезендә башкарыла.

Агентлыкның кадрлар резервына кертүгә Конкурс Агентлыкның юридик бүлеге тарафыннан ел саен Агентлыкның граждан хезмәте вакантлы вазыйфаларын һәм Агентлыкның кадрлар резервы булган кадрлар резервын биләү өчен белгечләргә ихтыяҗын бәяләү нәтиҗәләре буенча оештырыла.

Агентлыкның кадрлар резервына кертүгә Конкурс Агентлыкның конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.4. Агентлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга Конкурс үткәрелми:

а) «җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләрендә Агентлыкта билгеле бер вакытка биләп торган граждан хезмәте вазыйфаларын билгеләгәндә;

б) ашыгыч хезмәт контрактын төзегәндә;

в) Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә, 31 статьясындагы 1 өлешендә һәм 60.1 статьясындагы 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен башка дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә;

г) граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәре (граждан) вазыйфасына билгеләгәндә;

1.5. Агентлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга Конкурс үткәрелмәскә мөмкин:

Агентлык боерыгы белән расланган вазыйфалар исемлеге буенча дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне куллануга бәйле булган аерым граждан хезмәтенең вазыйфаларына билгеләнгәндә;

Агентлык җитәкчесе карары буенча, кече граждан хезмәте вазыйфаларының төркеменә караган граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнгәндә.

1.6. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел хокукларын, аларның сәләтләренә һәм һөнәри әзерлекләренә туры китереп, шулай ук конкурс нигезендә граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи үсешенә хокуклары белән тәэмин итү;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә торган кандидатларның гомуми санынннан һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми санынннан граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә иң туры килә торган кандидатларны сайлап алу;

граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Агентлык кадрлар резервын формалаштыру.

1.7. Конкурслар үткәргәндә хәл ителә торган бурычлар:

конкурс биремнәрен һәм процедураларны үтәгәндә барлык кандидатлар өчен тигез шартлар тәэмин итү;

кандидатларны граждан хезмәте культурасына туры килү, һөнәри компетентлык һәм шәхси-эшлекле сыйфатлар критерийлары нигезендә бәяләү;

Агентлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервы граждан хезмәте вазыйфасы) таләпләренә туры килә торган конкурста катнашучылар арасында конкурс биремнәрен үтәү нәтиҗәләрен чагыштыру һәм конкурс процедураларын узу юлы белән билгеләү.

Агентлыкта конкурсны оештыру «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» (алга таба - Бердәм кадрлар мәгълүмат системасы) Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын кулланып гамәлгә ашырыла.

## 2. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм эш тәртибе

2.1. Агентлыкта конкурслар үткәрү өчен Агентлык боерыгы белән даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе оештырыла. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затларның персональ составы үзгәргәндә, Агентлык боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2. Конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән комиссия рәисе җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, аның хокукларын һәм вазыйфаларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе эшен тәэмин итә (гаризалар кабул итү, эшләр формалаштыру, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерү һ. б.).

2.4. Агентлыкның конкурс комиссиясе составына Агентлык җитәкчесе, Агентлык җитәкчесе урынбасарлары, Агентлыкта кадрлар эше өчен җаваплы хезмәткәр, юридик бүлек башлыгы, конкурс үткәрелә торган бүлекчә вәкиле, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Агентлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре, экспертларның персональ мәгълүматларын күрсәтмичә генә Агентлык соравы буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты чакырыла торган экспертлар - граждан хезмәте белән бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр керә.

Агентлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре кандидатуралары, конкурс комиссиясе составына кертү өчен, Агентлык җитәкчесе соравы буенча, әлеге Совет тарафыннан тәкъдим ителә.

Агентлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне куллануга бәйле булган дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе составы, конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыклары барлыкка килү мөмкинлеге төшереп калдырылсын өчен төзелә. Агентлык җитәкчесе карары белән ел саен конкурс комиссиясе составы яңартыла.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасы) биләп торуга кимендә ике кандидат булганда уздырыла һәм, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче комиссия әгъзалары катнашында гына уздыру рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Тавыш биргәндә конкурс комиссиясе әгъзаларының фикере «аның өчен», «каршы», «тыелып калу» сүзләре белән әйтелә. Тавыш тигез булганда конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

2.9. Конкурста катнашучыларга карата конкурс комиссиясе түбәндәге карарлар кабул итә:

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә куела торган таләпләргә иң туры килә, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү өчен тәкъдим ителә;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә куела торган таләпләргә туры килә, Агентлыкның кадрлар резервына кертү өчен тәкъдим ителә;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә куела торган таләпләргә туры килми.

2.10. Конкурс комиссиясе карары кандидатның булмавында кабул ителә һәм аны Агентлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү (аның ризалыгы белән кадрлар резервына кертү) яисә бу эштән баш тарту өчен нигез булып тора.

2.11. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре конкурс комиссиясе карары белән граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс йомгаклары һәм утырышта катнашкан комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретарь һәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган кадрлар резервына кертүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Шул ук вакытта конкурс комиссиясе тарафыннан граждан хезмәте вазыйфасына беренче тапкыр билгеләнә торган граждан өчен сынау вакытының дәвамлылыгы буенча яисә граждан хезмәткәрен Агентлыкта граждан хезмәте вазыйфасының бүтән төркем яисә категориягә күчергәндә тәкъдим ителергә мөмкин.

2.12. Конкурсны оештыру һәм үткәрү, конкурс комиссиясе эшен Агентлык комиссиясе секретаре гамәлгә ашыра.

## 3. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста катнашуга әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны әлеге Нигезләмәнең 3.8 пунктында каралган срокта биргән Россия Федерациясе гражданнары (алга таба - гражданнар), шулай ук Агентлыкта вакантлы вазыйфаны биләү (кадрлар резервына кертү) өчен квалификация таләпләренә җавап бирүче граждан хезмәткәрләре рөхсәт ителә.

3.2. Граждан (граждан хезмәткәре) граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасы) биләү өчен квалификация таләпләренә туры килмәгәндә, шулай ук Федераль законда билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә конкурста катнашырга рөхсәт ителми.

3.3. Агентлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга (кадрлар резервына кертүгә) кандидатларга карата таләпләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында законнары нигезендә билгеләнгән.

3.4. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы Агентлыкка тапшыра:

а) шәхси гариза (әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы);

б) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тутырылган һәм имзаланган анкетаны фотография белән;

в) паспорт күчермәсе яисә аны алмаштыручы документ (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән тапшырыла);

г) кирәкле һөнәри белем, квалификацияне һәм эш стажын раслаучы документлар:

эш (хезмәт) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте белән раслаган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш) яисә гражданның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслаучы башка документлар күчермәсе;

белем бирү һәм квалификация турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданин теләге буенча өстәмә һөнәри белем бирү нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки тапшыруны раслаучы документлар күчермәләре, эш (хезмәт) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турында документлар;

д) гражданда граждан хезмәтенә керүгә яки аны узуга комачаулаучы авыру булмавы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге № 984н боерыгы белән расланган 001-ГС/у исәпкә алу формасы);

е) Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.

3.5. Конкурста катнашырга теләк белдергән Агентлыкның граждан хезмәткәре Агентлык җитәкчесе исеменә гариза бирә.

3.6. Конкурста катнашырга теләк белдергән башка дәүләт органында вазыйфа башкаручы граждан хезмәткәре Агентлыкка Агентлык җитәкчесе исеменә һәм ул имзалаган һәм граждан хезмәткәре граждан хезмәте вазыйфасын биләгән дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан расланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча фотография белән анкетаны тапшыра.

3.7. Граждан (граждан хезмәткәре) ризалыгы белән, граждан (граждан хезмәткәре) биләп торуга граждан дәгъва белдерә торган граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү серне тәшкил итүче белешмәләрне куллануга бәйле булса, дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләргә аны рәсмиләштерү процедурасы үткәрелә.

Граждан тарафыннан Агентлыкка бирелгән белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә бирелгән белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган тикшерүгә дучар ителә.

Граждан хезмәткәрләренә бирелгән белешмәләрнең дөреслеген тикшерү аның Агентлыкта граждан хезмәте вазыйфаларының югары төркеменә караган граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләп торуга конкурста катнашкан очракта гына гамәлгә ашырыла.

3.8. Әлеге Нигезләмәнең 3.4-3.6 пунктларында күрсәтелгән документлар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Агентлык рәсми сайтында (http://tida.tatarstan.ru) һәм «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмати системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы сайтында (http://www.gossluzhba.gov.ru) аларны кабул итү турында белдерү урнаштырылганнан соң 21 календарь көн эчендә Агентлыкка граждан (граждан хезмәткәрләренә) шәхсән, почта аша яки электрон рәвештә күрсәтелгән мәгълүмат системасын кулланып тапшырыла.

Документларны электрон рәвештә тапшыру тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

3.9. Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә яки җитди сәбәпсез рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда, гражданга (граждан хезмәткәренә) аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә яки җитди сәбәп аркасында рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда Агентлык җитәкчесе аларны кабул итү вакытын күчерергә хокуклы.

## 4. Конкурсны үткәрү методикасы

4.1. Конкурсны үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына нигезләнгән конкурс биремнәре һәм процедуралар кулланыла, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми. Конкурс процедуралары барышында кандидатларны бәяләү өчен бәяләүнең кимендә өч методы кулланыла.

4.2. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу алар тарафыннан конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын узу нәтиҗәләре нигезендә башкарыла.

4.3. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.3.1. Беренче этапта кадрлар эше өчен җаваплы хезмәткәр оештыра:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Агентлык рәсми сайтында (http://tida.tatarstan.ru) һәм «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмати системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы сайтында (http://www.gossluzhba.gov.ru) конкурс үткәрү турында мәгълүмат әзерләү һәм урнаштыру. Конкурс үткәрү турында белдерүдә түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла:

- дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфалары) атамасы;
- әлеге вазыйфаны биләп торуга квалификация таләпләре;
- граждан хезмәтен узу шартлары;
- тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты;
- әлеге документлар кабул ителә торган вакыты;
- конкурсны үткәрү өчен фаразланган көн;
- аны үткәрү урыны һәм тәртибе;
- бәяләү методлары турында мәгълүмат;

- граждан хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен хокуклар һәм җаваплылык, һөнәри хезмәт эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге һәм эффективлыгы күрсәткечләрен үз эченә алган граждан хезмәткәренең вазыйфаи регламенты нигезләмәләре;

- федераль порталда урнаштырылган беренчел тестка сылтама;

- башка мәгълүмати материаллар.

граждан (граждан хезмәткәрләренә) тапшырылган документларны тикшерү;

граждан (граждан хезмәткәре) квалификация таләпләренә (һөнәри белем дәрәҗәсе, граждан хезмәтенең (дәүләт хезмәтенең башка төрләрнең) стажы яки белгечлек буенча эш стажы (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, һөнәри белемнәр һәм вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле күнекмәләр) туры килү-килмәүне тикшерү.

4.3.2. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә граждан хезмәтенә керүгә комачаулаучы хәлләрне билгеләгәндә, ул Агентлык җитәкчесе тарафыннан язма рәвештә конкурста катнашудан баш тарту сәбәпләре турында хәбәр ителә. Граждан конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырса, конкурста катнашудан баш тарту сәбәпләре турында белдерү аңа көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт системасын кулланып, электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.3.3. Агентлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста катнашуга кертелмәгән претендент бу карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

4.3.4. Конкурсның беренче этабын тәмамлау шарты булып Агентлыкта билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килә торган граждан хезмәтенең (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасы) вакант вазыйфасына кимендә ике кандидатның булуы тора, бу исә кандидатларны киләчәктә сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаса яки вазыйфага квалификация таләпләренә туры килгән бер генә кандидат булса, конкурс үткәрелмәгән дип таныла. Бу очракта бердәнбер кандидатка, конкурс комиссиясе карары буенча, кандидатларның таләп ителгән саны булмау сәбәпле, конкурс үткәрелмәгән дип язма хәбәр ителә.

4.3.5. Конкурсның беренче этабы нәтиҗәсе булып, билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килә торган һәм конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан расланган конкурста алга таба катнашырга тәкъдим ителгән кандидатлар исемлеге тора.

4.3.6. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач, Агентлык җитәкчесе конкурсның икенче этабын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Конкурсның икенче этабы конкурста катнашу өчен документлар кабул итү тәмамланганнан соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча үткәрелә, ә дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләргә рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта, конкурсның икенче этабын үткәрү вакыты Агентлык җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

4.3.7. Агентлык конкурсның икенче этабы башланырга 15 календарь көннән дә соңга калмыйча аны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, конкурста катнашуга кертелгән гражданнар (граждан хезмәткәрләре) исемлеген «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Агентлык рәсми сайтында (http://tida.tatarstan.ru) һәм «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмати системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы сайтында (http://www.gossluzhba.gov.ru) урнаштыра һәм аларга язмача, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә биргән конкурста катнашырга рөхсәт ителгән гражданнарга (граждан хезмәткәрләренә) - әлеге мәгълүмат системасын кулланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында тиешле хәбәрләрне юллый.

4.3.8. Конкурсның икенче этабында гамәлгә ашырыла:

кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү;

Агентлык җитәкчесе тарафыннан Агентлыкның граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертүгә) конкурста җиңүчене билгеләү турында карар кабул итү.

4.3.9. Конкурс үткәрү барышында конкурс комиссиясе кандидатларны белем алу, граждан яки башка дәүләт хезмәтен узу, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турындагы документлар нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәгән методлар кулланып, конкурс процедуралары нигезендә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү, шул исәптән тест, анкеталау (үз-үзеңне презентацияләү)

һәм Агентлыкта дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын башкаруга (кадрлар резервы граждан хезмәте вазыйфаларына) кандидатлар дәгъва итә торган вазыйфалар башкару белән бәйле сораулар буенча шәхси әңгәмә формасында бәяли.

Һәр конкурс биремен үтәгән өчен максималь баллар 4.3.10, 4.3.11, 4.3.12 пунктлары нигезендә һәм биремне үтәлгән дип санарга мөмкинлек бирә торган максималь балл проценты № 2 Кушымтада күрсәтелгән.

4.3.10. Тест узуны оештыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт органыннан Бердәм мәгълүмат кадрлар системасында кергән гаризалар буенча гамәлгә ашырыла.

Тест үткәрү өчен гаризаны кадрлар хезмәте Бердәм мәгълүмат кадрлар системасында конкурс комиссиясе утырышына кадәр ике атнадан да соңга калмыйча формалаштыра.

Тест Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган тест методикасы нигезендә Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест үткәрүне оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге № УП-1192 Указы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.3.11. Анкеталау.

Анкета кандидатның үз-үзен күрсәтүеннән тора, ул кандидатның моңарчы һөнәри эшчәнлек кысаларында биләгән вазыйфалар буенча башкарыла торган вазыйфалар, профессиональ казанышлар, ул катнашкан чаралар (проектлар, форумнар, семинарлар һ.б.), кандидатның матбугатта басылып чыккан басмалар, мавыгулар, шулай ук кандидат тарафыннан бирелә ала торган тәкъдимнәр һәм (яки) тәкъдим итү хатлары турында сорауларны үз эченә ала.

4.3.12. Тест узган кандидатлар белән шәхси әңгәмә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан үткәрелә.

Шәхси әңгәмә кандидатларның булачак һөнәри хезмәт эшчәнлеге темасы буенча конкурс комиссиясе тарафыннан бирелә торган сорауларга телдән җавап бирүләреннән гыйбарәт, алар барышында конкурс комиссиясе кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен тиешле квалификация таләпләреннән һәм бу вазифа буенча вазыйфаи регламентның башка нигезләмәләреннән чыгып бәяли, шулай ук әлеге Нигезләмә һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында законнары белән билгеләнгән башка таләпләрдән чыгып бәяли.

Кандидат белән индивидуаль әңгәмә тәмамлангач, конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы конкурс бюллетененә кандидатны бәяләү нәтиҗәсен, кирәк булганда, конкурс комиссиясе әгъзасы кабул иткән карарны нигезли торган кыска мотивировка белән кертә.

Кандидатлар тарафыннан конкурс биремнәрен үтәгәндә һәм Агентлык җитәкчесе карары буенча конкурс комиссиясе утырышын үткәргәндә видео - һәм (яки) аудиоязма яисә тиешле конкурс процедураларын үткәрү стенограммасы алып барыла.

4.4. Конкурсның икенче этабы нәтиҗәсе һәм конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән конкурс комиссиясе карары тора.

4.5. Агентлыкта конкурска йомгак ясау һәм граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидат турында карар кабул итү өчен нигезләр булып кандидатлар алган тавыш саны тора.

Иң күп балл җыйган кандидат конкурста җиңүче дип таныла.

4.6. Әгәр конкурс үткәрү нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасын) биләп торуга квалификация таләпләренә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, Агентлык җитәкчесе кабат конкурс үткәрү турында карар кабул итә ала.

4.7. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс нәтиҗәләре буенча Агентлык тарафыннан конкурста җиңүчене граждан хезмәте вакантлы вазыйфасына билгеләү турында боерык чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә. Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим итү характерында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңүче булмаган, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган кандидат Агентлыгының кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Бу кандидатның гомуми баллар суммасы максималь баллның кимендә 50 процентын тәшкил итәргә тиеш.

Кандидат ризалыгы белән, аны шул ук төркемнең граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервына кертү турында Агентлык боерыгы чыгарыла.

Конкурста җиңүче граждан хезмәткәрен (гражданинны) кадрлар резервына кертү Агентлык боерыгы белән Агентлык боерыгының күчермәсен граждан хезмәткәренең шәхси эшенә җәлеп итү белән рәсмиләштерелә.

4.8. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

4.9. Конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрләр 7 көн эчендә ул тәмамланганнан соң кандидатларга язма рәвештә җибәрелә, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга - «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмати системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып (http://www.gossluzhba.gov.ru), көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шул ук вакытта «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Агентлык рәсми сайтында (http://tida.tatarstan.ru) һәм күрсәтелгән мәгълүмат системасы сайтында урнаштырыла.

4.10. Агентлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста катнашуга кертелмәгән претендентларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары аларга конкурс тәмамланганнан соң өч ел эчендә язма гариза буенча кире кайтарылырга мөмкин. Әлеге вакыт чыкканчы документлар агентлык архивында саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тәкъдим ителгән документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң бетерелергә тиеш.

4.11. Конкурста катнашу (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынын наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б.) белән бәйле чыгымнар кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәгә 1 нче кушымта
2018 елның 31 июленнән № 34

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесенә
________________________________
(инициаллар, фамилия)
________________________________,
(фамилия, исем, ата исеме)
белеме___________________________
________________________________,
(төре, уку йорты, уку елы)
адрес буенча яшәүче:____________
________________________________
тел.____________________________,
(эш, өй, мобиль)
e-mail___________________________

Гариза

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста катнашуга рөхсәт итүегезне сорыйм
________________________________________________________________________
(вазыйфаның һәм структур бүлекчәнең атамасы)

"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль закон, "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында" Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге № 112 Указы, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы законы, Россия Федерациясе һәм Татарстан

Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында башка норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында Нигезләмә, шул исәптән әлеге вазифага куела торган квалификация таләпләре белән таныш. "Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге № 152-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза.

Дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматларга рөхсәтне рәсмиләштерү процедурасын үткәрү белән килешәм.

Конкурсны үткәрү датасы һәм урыны турында e-mail яки СМС-хәбәрләр аша күрсәтелгән мобиль телефон номерына хәбәр итүгә риза.

Гаризага кушымта итеп бирәм:

___________________________________________________________________________

(кушымта итеп бирелә торган документларны атарга)

____________________ ______________________

___________________________________

(дата) (имза) (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәгә 2 нче кушымта
2018 елның 31 июленнән, № 34

Һәр конкурс биремен үтәгән өчен максималь балл һәм биремне үтәгән дип санарга мөмкинлек бирә торган максималь балл проценты

| Бәяләү методы | Максималь балл | Биремне үтәгән дип санарга мөмкинлек бирә торган максималь балл проценты |
|---|---|---|
| Тест | 10 | 60 |
| Анкеталау (үзпрезентация) | 10 | 60 |
| Шәхси әңгәмә | 10 | 60 |